**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы
**КАРАРы**

2023 елның 07 июне № 28 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 26.10.2020 № 12 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү буенча Иҗтимагый совет турында Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының һәм федераль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләре сыйфатын бәйсез бәяләүне камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 05 декабрендәге 392-ФЗ номерлы Федераль закон, "Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәләрендәге оешмалар һәм Федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүмат җыю һәм гомумиләштерү кагыйдәләрен раслау турында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 31.05.2018 № 638 карары белән, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 13.07.2018 № 55-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 31.12.2022 № 109-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 26 октябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру буенча иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы

Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе указларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм күрсәтмәләренә, муниципаль хокукый актларга, шулай ук әлеге нигезләмәгә таяна.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы<br>
Ютазы муниципаль районы<br>
Башлыгы -<br>
Татарстан Республикасы<br>
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин